Танышты

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башлыгы Л.Р.Зариповка

Хөрмәтле Ленар Рафакович!

2024 елның 2 кварталында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау нигезендә аларның саны һәм эчтәлеге турында мәгълүмат бирелә.

Күрсәтелгән чор дәвамында 106 язма һәм телдән мөрәҗәгать килгән, бу 2023 елның шул ук чоры белән чагыштырганда 1 %ка югарырак (105).

Татарстан Республикасы Рәисе администрациясе аша кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре саны 20 %ка кимеде һәм 8 (2023-10) тәшкил итте.

Электрон элемтә аша 21 мөрәҗәгать килгән (2023 ел -10), бу узган ел белән чагыштырганда 47,6% ка күбрәк.

Аноним гаризалар каралган корреспонденцияләр арасында юк, (2023-0). Коллектив мөрәҗәгатьләр саны 11 (имзалар саны 567) (2023-5/56).

Иң күп мөрәҗәгатьләр Актаныш авылында яшәүчеләрдән – 38 мөрәҗәгать (33,3 %) һәм Пучы авылыннан-5 (4,4%) мөрәҗәгать килгән.

Гражданнар корреспонденциясенең тематик классификациясе икътисадый юнәлешле мәсьәләләрнең өстенлеге турында сөйли - 38 мөрәҗәгать, бу алдагы хисап чорыннан 50 процентка югарырак (2023 ел - 19). Алар арасында хуҗалык эшчәнлеге мәсьәләләре 31 мөрәҗәгатьтә күтәрелә, атап әйткәндә, шәһәр төзелеше һәм архитектура - 14, транспорт - 10, авыл хуҗалыгы - 4; табигый ресурслар һәм әйләнә-тирә табигый мохитне саклау тематикасы буенча 6 мөрәҗәгать килгән.

2024 елның 2 кварталында иҗтимагый-сәяси тормыш 16 мөрәҗәгатьтә яктыртылды (2023 ел – 28). Әлеге блокта дәүләтнең сәяси корылышы һәм гражданнар җәмгыяте белән бәйле мәсьәләләр карала. Конституцион корылыш нигезләренә - 7 мөрәҗәгать, дәүләт идарәсе нигезләренә - 6 мөрәҗәгать багышланган.

Социаль даирәгә гражданнарның 23 мөрәҗәгате (2023 ел - 33) кагыла, алар мәгариф, фән һәм мәдәният -10; халыкны социаль тәэмин итү һәм социаль иминләштерү - 6; сәламәтлек саклау - 5; гаилә - 1; хезмәт һәм халыкның мәшгульлеге - 1 мөрәҗәгатьне үз эченә ала.

Торак-коммуналь өлкә мәсьәләләре гражданнарның 29 мөрәҗәгатендә каралган (2023 ел - 27). Билгеләнгән темада күпчелек өлешне коммуналь хуҗалык белән бәйле мәсьәләләр алып тора - 18, атап әйткәндә, 6 су белән тәэмин итү белән бәйле өзеклекләр; гражданнарны торак белән тәэмин итү, торак фондыннан файдалану, торак өлкәсендә социаль гарантияләр - 5;

Мөрәҗәгатьләрнең иң аз саны законлылык һәм хокук тәртибен саклау мәсьәләләре буенча тематикада - 4 (2023 ел - 4) каралды. Иминлек һәм хокук тәртибен саклау турында - 2; хәрби хезмәт -2 тема күтәрелде.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча башкаручылардан 74 җавап алынды; 11 мәсьәлә уңай хәл ителде; 38 гражданга аңлатмалар бирелде.

Гомуми бүлек башлыгы Н.Ф.Сарварова